**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

________________ ПР-168 от 13.08.2025 № ______

Гавами тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Актанышбаш авыл җирлеге адресы буенча урнашкан «Актаныш нефть ятмасы К-161 скважиналары кустын төзекләндерү» линияле объектын урнаштыру буенча халык алдында тыңлаулар билгеләргә.

2. Иҗтимагый фикер алышуларны (гавами тыңлауларны) оештыручы – коллегиаль киңәшмә органы составын расларга:

1) Маликов Гадел Рөстәм улы;

2) Зәйнетдинов Булат Рифат улы;

3) Зәйнуллина Чулпан Хамис кызы;

4) Гобәева Ирина Ришат кызы.

3. Иҗтимагый фикер алышуларны (гавами тыңлауларны) оештыручыга Актанышбаш авыл башкарма комитетына җирле үзидарә турындагы законнар, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә иҗтимагый фикер алышулар (гавами тыңлаулар) оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Иҗтимагый фикер алышуларны (гавами тыңлауларны) уздыруны 08.09.2025 елга кадәр тәмамланырга тиеш дип билгеләргә.

5.Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, https://aktanysh.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Ш.Бариев